**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**мәгариф һәм**
**фән министры**
**___________ И.Г.Һадиуллин**
**«___» _________ 2022 нче ел**

# Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен 2023 нче елда туган (татар) әдәбияттан бердәм республика имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2023 году единого республиканского экзамена по родной (татарской) литературе для учащихся школ с родным языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## Күрсәтмә вариантка аңлатма

Татар әдәбиятыннан бердәм республика имтиханының (БРИ) күрсәтмә варианты дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерләнүчеләргә йөз тотып төзелде. Шуны истә тотарга кирәк: әлеге вариант имтиханда тәкъдим ителәчәк биремнәрне тулысынча чагылдырмый. Аның төп максаты – укучыларга бердәм республика имтиханына мөстәкыйль әзерләнергә юнәлеш бирү.

Күрсәтмә вариант укучыларда контроль-үлчәү материалларының структурасы, биремнәрнең күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Мөстәкыйль әзерлек барышында укучыларга файдалану өчен биремнәргә җаваплар да тәкъдим ителә. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм, гомумән, киң җәмәгатьчелектә бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый.

Әлеге мәгълүматлар укучыларга татар әдәбиятыннан бердәм республика имтиханына әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итә.

## Имтихан эшен башкару өчен күрсәтмә

Имтихан эшен башкару өчен 210 минут вакыт бирелә. Татар әдәбиятыннан бердәм республика имтиханы биремнәре 3 бүлектән гыйбарәт.

Беренче һәм икенче бүлекләрдәге биремнәр тәкъдим ителгән әдәби текстларга эчтәлек һәм форма ягыннан анализ ясауны күздә тота. Текстларны башта игътибар белән уку, бары шуннан соң гына әсәргә яки тәкъдим ителгән өзеккә карата куелган сорауларга җавап бирә башлау мөһим.

Эпик яки драма әсәренә анализны үз эченә алган беренче бүлектә бер сүз яки сүзтезмә белән җавап язу юнәлешендә 7 сорау һәм киңәйтелгән җавап таләп итүче 2 сорау тәкъдим ителә.

Лирик әсәргә анализны үз эченә алган икенче бүлектә бер сүз яки сүзтезмә белән җавап язу юнәлешендә 5 сорау һәм киңәйтелгән җавап таләп итүче 2 сорау тәкъдим ителә.

Җавап язу барышында төгәл эш таләп ителә. Эпик һәм лирик әсәргә киңәйтелгән анализ таләп иткән биремнәргә җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә, 5-10 җөмлә күләмендә формалаштыру кирәк. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Беренче, икенче бүлекләрдә сорауга төгәл җавап табылмый икән, авырлык тудырган сорауларны калдырып торырга, өченче өлештәге биремнәрне үтәргә, эшләнми калган биремнәргә соңыннан әйләнеп кайтырга мөмкин.

Өченче бүлек өч биремне үз эченә ала. Алар әдәбиятның аерым чорларына яки әдипләр иҗатына, әдәби процесстагы үзенчәлек-хасиятләргә бәя бирүне күздә тота. Җавап бирү барышында биремнәрнең БЕРСЕНӘ генә сочинение формасында киңәйтелгән җавап язу сорала.

Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, һәр биремгә бер яки аннан артык балл куела, ахырда бөтен баллар бергә кушылып, нәтиҗә чыгарыла.

**Уңышлар телибез!**

# 1 НЧЕ БҮЛЕК

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез.**

Авыр тойгылар белән мин бу йортның капкасына барып сугылдым. Әүвәл заманнарда көне буе ачык була, аның аркылы өзлексез йөрелеп торыла торган бу картайган капка хәзер эчке яктан бикләп куелган иде.

Иске, тузанлы, бераз бүртенгән бер сүс арканны тарттым да ишегалды эчендә шалтыраган кыңгырауның яңгырашын тыңлап тордым: ул әллә ничек тупас һәм моңлы шалтырый да искергән һәм кытыршыланган тавыш чыгара иде. Таш койма һәм таш капкалар аркылы сизелеп тора торган серле тынлыкка баткан ишегалды бу яңгыраштан ыңгырашып куйды. Берничә минуттан соң инде аның эчендә ниндидер бер хатынның картлык йөткереше белән йөткерә-йөткерә чыгып килгәнлеге сизелде. Тагы бераздан соң минем алдымдагы авыр капка ыңгырашып кына, теләми генә ачылган төсле ачылды. Аның эченнән күренгән озын буйлы, бер күзенә ак төшкән куркыныч кыяфәтле карчык, кем икәнлегемне бик җентекләп сорашканнан соң гына, мине ишегалдына кертте.

Биек таш койма белән чолганган киң һәм озын бу ишегалды, таш белән түшәлгәнлегенә карамыйча, ямь-яшел үләнлеккә әйләнгән, әүвәл заманнарда гөрләп, шаулап торган бу ишегалды хәзер әллә нинди серле тынлык, җанны авырайта торган тынлыкка батып калган иде. Ишекләре кәкрәйгән сарайлар, урыны-урыны белән түбә калайлары купкан амбарлар, ташланган кое, түрдә күренеп торган, искергән һәм бераз артка таба ауган рәшәткәле бакча коймасы бу хәятсыз ишегалдына әллә нинди, җанга авыр булып торган шыксызлык һәм ташландыклык төсе биреп тора иде.

Мин ишегалдына кереп җиткәч, өрәк төсле озын буйлы, берсе ак, берсе кара күзле карчык, йөткеренә-йөткеренә, капканы тагы бикләп куйды да, сүз дәшмичә генә, яңадан бер кат мине баштанаяк карап чыкты. Таш койма, бикле авыр таш капка бу карчык белән мине бөтен хәятлы дөньядан, бөтен адәм кыяфәтле кешеләрдән аерып торалар иде. Бу кыяфәтсез карчык белән бу хәрабә ишегалдында ялгыз калганлыгымны күргәч, мин, куркына башлаган шикелле, җәһәт-җәһәт өй ишегенә таба атладым. Кайчандыр бөтенлектән, чисталыктан ялтырап тора торган бу ишек хәзер каралган, сүнгән, пычранган, кырылып беткән килеш, алдындагы сүсәреп яшелләнгән һәм кыегайган баскычларына карап җылаган шикелле итеп тора иде.

Мин баскычларның берсенә аягымны куям дигәндә, артымнан килә торган карчык, йөткеренә-йөткеренә:

– Чү, анда ярамый! – дип кычкырып җибәрде. Аннан соң игътибарсыз гына, карамый гына мине узып китте дә үзенең җеннәренә сөйләп барган сымак кыяфәт һәм әллә нинди төссез тавыш белән: – Күптән өйнең ул ягында кеше тормый. Анда бичура ияләнгән, – диде.

*Ф.Әмирхан «Бер хәрабәдә»*

**Бер сүз яки сүзтезмә белән җавап таләп иткән биремнәргә җавабыгызны регистрация һәм җаваплар бланкының беренче битенә урнаштырыгыз. Биремнәргә җавабыгызны шушы бирем номерының уң ягына беренче шакмактан башлап сүз яки сүзтезмә рәвешендә языгыз. Һәр хәрефне аерым шакмакка ачык итеп языгыз. Сүзләр янына бернинди дә тыныш билгеләре куелмый һәм буш шакмаклар калдырылмый.**

**1** Сайланган әсәрнең кайсы әдәби төргә каравын ачыклагыз һәм җавапта языгыз.

Җавап: ___________________.

**2** Әлеге әсәрнең кайсы әдәби жанрга каравын билгеләгез һәм җаваплар бланкына языгыз.

Җавап: ___________________.

**3** Өзекнең беренче абзацында урын алган, Сөләйман абзый йортын тышкы дөнья белән аерып торган, шартлы мәгънәгә ия булган образны табыгыз һәм җаваплар бланкына язып куегыз.

Җавап: ___________________.

**4** Тәкъдим ителгән образларны һәм әсәр сюжетындагы аларга хас сыйфатларны тәңгәлләштерегез. Икенче баганадан беренче баганадагы образга туры килгән детальне сайлап алыгыз.

Образлар:

А) Ишегалды;

Б) Карчык;

В) Кыңгырау.

Детальләр:

1. Озын буйлы, бер күзенә ак төшкән куркыныч кыяфәтле;

2. Әллә ничек тупас һәм моңлы шалтырый да искергән һәм кытыршыланган тавыш чыгара;

3. Серле тынлыкка баткан.

Җавапта үзегез дөрес дип уйлаган җавап санын таблицадагы хәрефләргә туры китереп куегыз:

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

**5** Карчык образы кайсы образ (герой) төренә карый?

Җавап: ___________________.

**6** Өзектә Карчыкның тышкы кыяфәте җентекләп сурәтләнә. Аның әдәбият белемендәге атамасын языгыз.

Җавап: ___________________.

**7** «Кайчандыр *бөтенлектән, чисталыктан ялтырап тора торган* бу ишек хәзер *каралган, сүнгән, пычранган, кырылып беткән* килеш, алдындагы сүсәреп яшелләнгән һәм кыегайган баскычларына карап җылаган шикелле итеп тора иде» юлларында кулланылган лексик чараның төрен билгеләгез һәм җаваплар бланкына языгыз.

Җавап: ___________________.

**Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне үтәү өчен җаваплар бланкының икенче битен кулланыгыз. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, 5-10 җөмлә күләмендә эзлекле җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Биремгә җавап бирү барышында чагыштыру өчен китерелгән мисаллар ике әсәрдән дә ким булмаска тиеш. Бер үк авторның ике әсәрен мисалга китерергә дә мөмкин.**

**8** «Бер хәрабәдә» әсәрендә Ф.Әмирхан ни өчен йортның элеккеге һәм хәзерге сурәтен капма-каршы куеп сурәтли дип уйлыйсыз?

**9** Әлеге әсәрендә автор нинди проблемалар күтәрә, бу яктан ул кайсы әсәрләр белән аваздаш? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп языгыз.

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**Түбәндә тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез.**

Күңелгә минем, туган як,
Бигрәк тә якын шул син.
Кырларың өстеннән искән
Җилләргә хәтле сусыйм.

Тезләнәм чишмәләреңә,
Бетми тик сусау гына.
Мин бәхетле бары тик син
Бәхетле булсаң гына.

Ник болай сагышлы иттең,
Бу кадәр мине соң син?!
Аерылып бер көн дә узмый,
Яңадан сиңа сусыйм.

Ник болай гомерем буена
Бетмәгән сусау икән?
Сусаудан янган күңелгә
Су салып торсаң икән.

*С.Хәким «Сусау»*

**Бер сүз яки сүзтезмә таләп иткән биремнәргә җавабыгызны регистрация һәм җаваплар бланкының беренче битенә урнаштырыгыз. Биремнәргә җавабыгызны шушы бирем номерының уң ягына**, *беренче шакмактан башлап,* **сүз яки сүзтезмә рәвешендә языгыз. Һәр хәрефне аерым шакмакка ачык итеп языгыз, сүзләр янына берниндә дә тыныш билгеләре куймагыз.**

**10** Әлеге шигырьнең кайсы әдәби төргә каравын билгеләгез.
Җавап: ___________________.

**11** Шигырьнең беренче строфасында сусауның дәрәҗәсен, көчен, асылын җиткерергә ярдәм иткән образны языгыз.
Җавап: ___________________.

**12** Әлеге шигырьнең жанрын билгеләп языгыз.
Җавап: ___________________.

**13** Тәкъдим ителгән исемлектән шигырьнең соңгы строфасында кулланылган өч сурәтләү чарасын һәм алымын сайлап алыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсү тәртибендә языгыз.

1. Сынландыру;
2. Эпитет;
3. Антитеза;
4. Риторик сорау.

Җавап: ___________________.

**14** «*Ник болай сагышлы иттең, Бу кадәр мине соң син?!*» юлларында кулланылган, җөмләдә сүзләр тәртибенә нигезләнгән стилистик чараның төрен билгеләгез һәм җаваплар бланкына языгыз.
Җавап: ___________________.

**Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне үтәү өчен җаваплар бланкының икенче битеннән файдаланыгыз. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, 5-10 җөмлә күләмендә җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Биремгә җавап бирү барышында чагыштыру өчен китерелгән мисаллар ике әсәрдән дә ким булмаска тиеш. Бер үк авторның ике әсәрен мисалга китерергә дә мөмкин.**

**15** Шигырьгә таянып, «*Мин бәхетле бары тик син / Бәхетле булсаң гына*» юлларына салынган мәгънәне аңлатып языгыз.

**16** Шигырьдә лирик геройга хас сыйфатларны ачыклагыз. Мондый тип лирик герой тагын кайсы авторларның шигырьләрендә урын ала? Җавабыгызны дәлилләгез.

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**3 нче бүлек биремнәрен үтәү өчен җаваплар бланкының икенче битеннән файдаланыгыз. Җавап бирү барышында тәкъдим ителгән биремнәрнең бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Үзегез сайлаган биремгә, әдәби материалга таянып, киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш, 150 сүздән дә ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә. Җаваплар бланкында сайлап алган биремегезнең номерын күрсәтегез.**

**17.1** К.Насыйриның «Әбугалисина кыйссасы»нда мәгърифәтчелек идеяләре. Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

**17.2** М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында күтәрелгән проблемалар. Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

**17.3** М.Әгъләмов иҗатында урын алган лирик герой үзенчәлеге. Фикерләрегезне мисаллар белән дәлилләгез.

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН**
**БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫ ЭШЕН БӘЯЛӘҮ СИСТЕМАСЫ**

**Бер сүз яки сүзтезмә белән җавап таләп иткән биремнәргә җаваплар**

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | Эпик төр / Проза |
| 2 | Хикәя |
| 3 | Капка |
| 4 | 312 |
| 5 | Ярдәмче |
| 6 | Портрет |
| 7 | Антоним |
| 10 | Лирик төр < Поэзия |
| 11 | Җил / җилләр |
| 12 | Күңел лирикасы |
| 13 | 124 |
| 14 | Инверсия |

## КИҢӘЙТЕЛГӘН ҖАВАПЛАРНЫ ТАЛӘП ИТҮЧЕ БИРЕМНӘРНЕҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

**Игътибар!** «2 нче санлы биремнәр бланкының җавапларны тикшерү беркетмәсе»ндә җавапларга балл куйганда, шуны истә тотарга кирәк: **җавап булмаган очракта** (имтихан бирүче бу биремне эшли дә башламаган булса, бернинди язма да булмаса), беркетмәгә **«X»** куела, **«0»** куелмый.

**Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне (5-10 җөмлә күләмендә) бәяләү**

5-10 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) имтихан тапшыручы укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк | **3** |
| б) имтихан тапшыручы укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең | **2** |

| | |
|---|---|
| кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли / яки җавапта бер фактик хата күзәтелә | |
| в) имтихан тапшыручы сорауга өстән генә җавап бирә, үз фикерен күрсәтә, әмма автор позициясен төгәлләштереп бетерә алмый, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки 2 фактик хата ясалган | **1** |
| г) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **4** |

**Чагыштырма планда киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне (5-10 җөмлә күләмендә) бәяләү**

5-10 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

Җавапны тикшерү барышында беренче критерий буенча 0 балл куелса, җавап икенче критерий нигезендә тикшерелеп тормый.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **Тәкъдим ителгән әсәрнең әдәби контекстка кертелүе һәм җавапның нигезләнгән булуы** | |
| а) имтихан тапшыручы биремнең үзенчәлеген аңлый: әдәби контекстка куелган таләпне үтәп, төшенеп җавап бирә (күтәрелгән тема, проблема яки мотив, образ, әдәби чаралар һәм алымнар чагылышын тапкан ике-өч әсәрне һәм язучыны атый), сорауга төгәл җавап биргән, тиешле дәлилләр белән фикерен раслап бара, фактик хаталар ясамый | **4** |
| б) имтихан тапшыручы җавабында әдәби контекстны өлешчә файдалана (1 позиция), чагыштыруга өлешчә нигезләмә бирә (авторларны һәм әсәрләрен генә санап чыга), 2 әсәрнең исемен атый / яки җавапта 1 фактик хата ясый | **3** |
| в) имтихан тапшыручы җавабында әдәби контекстны өлешчә файдалана (1 позиция), чагыштыруга өлешчә нигезләмә бирә (авторларны һәм әсәрләрен генә санап чыга), 1 әсәрнең исемен атый / яки җавапта 2 фактик хата ясый | **2** |
| в) имтихан тапшыручы җавабында әдәби контекстны өлешчә генә файдалана (1 позиция), чагыштыруга нигезләмә бирми (авторларны яки әсәрләрнең исемнәрен дә күрсәтми) / яки | **1** |

| | |
|---|---|
| эчтәлеге ягыннан нигезләнгән җавапны язмый / яки җавапта 3 фактик хата ясый | |
| г) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми яки язмасының эчтәлеге биремгә туры килми / яки җавапта 3тән артык фактик хата ясый | **0** |
| **Иң югары балл** | **4** |

**Киңәйтелгән җавап таләп иткән биремнәрне (сочинение форматында) бәяләү**

3 нче бүлекнең бирем җаваплары биш критерий ярдәмендә бәяләнә, шулар арасында иң мөһиме, әһәмиятлесе булып беренчесе - эчтәлек санала. Тикшерү барышында җавапның эчтәлеге 0 балл белән бәяләнгән очракта бирем эшләнмәгән булып санала һәм **алга таба тикшерелми**. Калган (2, 3, 4, 5) бәяләү аспектлары буенча 2 нче биремнәрнең җавапларын тикшерү бланкына 0 балл куела.

Тикшерү барышында беренче позициянең баллы беркетмәнең 7 нче баганасына, икенче позициянеке – 8 нче баганага, өченче позициянеке – 9 нчы баганага, дүртенче позициянеке – 10 нчы баганага, бишенче позициянеке – 11 нче баганаларга куела.

3 нче өлешнең биременә җавапны бәяләгәндә, язылган иншаның күләме исәпкә алына. Укучыларга 200 сүздән ким булмаган күләмдәге текстны язу тәкъдим ителә. Әгәр инша тексты 150 сүздән ким булса, мондый эш үтәлмәгән дип санала һәм «0» балл белән бәяләнә.

| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
|---|---|
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, автор позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **3** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | **2** |
| в) сорауга җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 3-4 фактик хата күзәтелә | **1** |
| г) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлау, алар белән эшләү дәрәҗәсе** | **Балл** |

| | |
|---|---|
| а) әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр аңлап, урынлы кулланыла, җавап теоретик яктан югары дәрәҗәдә язылган | **2** |
| б) имтихан тапшыручы әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлый, әмма әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 төгәлсезлек күзәтелә | **1** |
| в) укучы әдәби-теоретик төшенчәләрне дөрес кулланмый яки әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматлы түгел, әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 дән артык хата ясый | **0** |
| **3. Җавапның, әдәби текстларны кулланып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **3** |
| б) җавап бирү барышында әсәрне (әсәрләрне) файдаланып та, җавапны дәлилли алмый, мисаллар нигезле түгел / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **2** |
| в) җавапта әсәрнең (әсәрләрнең) турыдан-туры эчтәлеге генә урын ала | **1** |
| г) җавап бирү барышында әсәр (әсәрләр) бөтенләй файдаланылмый, нигезләнми | **0** |
| **4. Җавапның эзлеклелеге, фикерне җиткерү мөмкинлеге** | **Балл** |
| а) җавап логик яктан эзлекле языла, фикерләр үзара бәйләнештә бирелә, төгәл җиткерелә | **3** |
| б) җавапның мәгънәви өлешләре үзара логик яктан эзлекле языла, әмма аерым кабатлаулар, төгәлсезлекләр күзәтелә | **2** |
| в) җавап эзлекле булып та, фикер еш кабатлана, төп темадан читкә киткән урыннар күзәтелә | **1** |
| г) җавап логик яктан эзлекле язылмаган, эзлеклелек тупас бозылган, җавапта гомуми мантыйк юк | **0** |
| **5. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) сөйләм хаталары юк яки 1 сөйләм хатасы ясалган | **3** |
| б) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **2** |
| в) 4 сөйләм хатасы ясалган | **1** |
| г) сөйләм хаталары бик күп (5 яки аннан да артык) булып, фикерне аңлауда кыенлыклар тудыра | **0** |
| *Иң югары балл* | ***14*** |